**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**С О В Е Т**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**С О В Е Т Ы**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**№ 62** **2019 елның 12 сентябре**

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм кертергә:

Нигезләмәнең 9.3 пунктында «кимендә 2 ай һәм 4 айдан да артык түгел» сүзләрен «кимендә бер ай һәм өч айдан дә артык түгел» сүзләренә алмаштырырга;

10.3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.Р. Метшин